РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«02» февраля 2022г. с. Тюлячи № 7

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында 2022 елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

Тарифлар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының 2022 елның 28 гыйнварындагы ЛХ-28/418/2022 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 1 февраленнән башлап, Теләче муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6964,68 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә, 1 номерлы кушымта нигезендә.

2. 2022 елның 1 февраленнән башлап Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясен, җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган авыл җирлекләрен дә кертеп, расларга, 2 номерлы кушымта нигезендә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы – территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б.Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«02» 02 2022 № 7
карарына 1 номерлы кушымта

2022 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 135,50 |
| 2. Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү | 2900,14 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка илтү, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 828,72 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 3100,32 |
| **Барлыгы:** | **6964,68** |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«02» 02 2022 № 7
карарына 2 номерлы кушымта

2022 елның 1 февраленнән башлап Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясен, җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган авыл җирлекләрен дә кертеп

| № т/б | Муниципаль берәмлек, авыл җирлекләре исеме | Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе - сум |
|---|---|---|
| 1. | Әбде авыл җирлеге | 6964,68 |
| 2. | Алан авыл җирлеге | |
| 3. | Айдар авыл җирлеге | |
| 4. | Баландыш авыл җирлеге | |
| 5. | Олы Мәтәскә авыл җирлеге | |
| 6. | Олы Нырсы авыл җирлеге | |
| 7. | Олы Мишә авыл җирлеге | |
| 8. | Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге | |
| 9. | Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге | |
| 10. | Үзәк авыл җирлеге | |
| 11. | Шәтке авыл җирлеге | |
| 12. | Иске Җөри авыл җирлеге | |
| 13. | Теләче авыл җирлеге | |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев